ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТАВЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАУИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ул. Нагорная, д.70, с. Тавели,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422160

Тау өсте урамы, 70 йорт, Тауиле авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы, 422160

т Тел. (факс): (85563) 2-67-25 e-mail: Tavel.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

---

Постановление | Карар

“22” ноябрь 2018 ел | № 18

### Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, нигезендә, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге территориясендә 2018 нче елның 19 нче ноябрендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында» 922 нче номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш районы территориаль сайлау комиссиясе карарын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Әлеге карарга теркәлеп килүче Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын җыю тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Мамадыш муниципаль районы
Тауиле авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /В.И.Иванов/

ТР Мамадыш муниципаль районы
Тауиле  авыл җирлеге башкарма
комитетының
22.11. 2018 ел, № 18 карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле  авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле  авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен әлеге тәртип билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары, җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле  авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнар тарафыннан, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек  Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия  Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елның 28 февраленә кадәр башкарыла.

3. Нигезле түбәндәге сәбәпләр булганда:

а) вакытлыча хезмәткә яраксызлык,

б) хезмәт командировкасы,

гражданнарга гариза нигезендә бер айдан да артык булмаган срокка түләүне кичектереп торырга мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында белдерү (хәбәрнамә) бланкы гражданнарга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, шулай ук шәхсән тапшыру юлы белән имза куйдырып яки почта элемтәсе аша  җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (белдерүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр бирелә торган түләү суммасы, аны түләү вакыты булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле  авыл җирлегенең шәхси счетына керә.

6. Түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле  авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша https://uslugi.tatarstan.ru (сылтама буенча), почта күчерүләрен (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша, аша башкарыла.

7. Түләү фактын раслау булып приход касса ордеры квитанциясе, чек-ордер квитанциясе, түләү фактынраслый торган башка документлар тора.

8. Билгеләнгән срокта кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары

законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

ТР Мамадыш муниципаль районы
Тауиле авыл җирлеге
башкарма комитетының
22.11. 2018 ел, № 18 карарына
2 нче кушымта

Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ № _______________

Түләүченең
Ф.И.А.и. ______________________________________________________________
Адресы: ___________________________________________________________

Татарстан Республикасы Мамадыш районы территориаль сайлау комиссиясенең 2018 нче елның 19 нчы ноябрендә кабул ителгән 903 нче номерлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында» карары нигезендә 2018 нче елның 18 нче ноябрендә Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү турында Карар кабул ителде.

Сезгә 2019 елның 28 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге территориясендә җирле референдум чараларын тормышка ашыру өчен бер тапкыр кертелә торган 400 сум күләмендә түләүне түбәндәге реквизитлар аша кертергә кирәк.

по следующим реквизитам: ТР буенча ФКИ (ТР Мамадыш муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы)
алучы Банк бүлеге - Татарстан Республикасы НБ БИК049205001
Сч. № 40101810800000010001
ИНН 1626008921 КПП 162601001
КБК 60511814030100000180 ОКТМО 92638415
Түләүнең билгеләмәсе
Гражданнарның үзара салым акчалары
Җитәкче _________________ О.Н.Павлов
М.У.

**- - - - - - - - - - - - - - - - - кисү өчен - - - - - - - - - - - - - -**

Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында Хәбәрнамә № _________________
400 сум күләмендә.
Түләүченекң Ф.И.А и.

_______________________________________________________

Адрес:__________________________________________________________________
Алды: «__» ________________ 20__ г. ____________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. хәбәрнамә түләүчегә шәхсән бирелгән очракта, киселгән өлеш Тауиле авыл җирлегенең башкарма комитетында тутырыла һәм шунда кала.*